СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**14.08.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 218**

Зеленодольск муниципаль районында экстремизм һәм террорчылыкны, аеруча мөһим объектларның террорчылыкка каршы сакланышын профилактикалау турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В. Старостинның Зеленодольск муниципаль районында экстремизм һәм террорчылыкны, аеруча мөһим объектларның террорчылыкка каршы сакланышын профилактикалау турындагы мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасының “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль районында экстремизм һәм террорчылыкны, аеруча мөһим объектларның террорчылыкка каршы сакланышын профилактикалау турында мәгълүматны игътибарга алырга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

2.1. Зеленодольск муниципаль районы территориясендә экстремизмга, террорчылыкка, хокук бозуларга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны кисәтүгә, ачыклауга, бетерүгә юнәлдерелгән системалы эшне дәвам итәргә;

2.2.2015-2017 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программаның программа чараларын башкару эшен активлаштырырга;

2.3. 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау буенча муниципаль программа эшләргә һәм расларга;

2.4. Яшьләрне , мәктәп һәм студентлар коллективларында, гаиләләрдә, формаль булмаган иҗтимагый оешмаларда һәм берләшмәләрдә радикализацияләүгә каршы юнәлдерелгән профилактик чаралар уздыруны тәэмин итәргә;

2.5 көч структураларына балаларның һәм яшьләрнең үз-үзләрен тотышында радикаль һәм формаль булмаган агымнар күренешләре ачыкланган (күренгән) фактлар турында мәгълүмат бирү;

2.6. Интернет челтәрендә балаларның мәгълүмати иминлеге мәсьәләләрен аерым контрольгә алырга һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә күрсәтелгән өлкәдә эшләрнең торышын даими рәвештә карарга;

2.7.экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалауда катнашуга иҗтимагый яшьләр оешмаларын җәлеп итәргә.

3. Кешеләр күпләп була торган урыннар объектлары җитәкчеләренә (ведомствога карамыйча) объектларны комиссия тикшерүләре актларында билгеләнгән кисәтүләр буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 мартындагы«Полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләрнең (территорияләрнең) күпләп булу урыннарының (территорияләрнең) террорчылыктан сакланылуына карата таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) куркынычсызлык паспортлары рәвешләрен раслау турында»» 272 номерлы карары таләпләренә туры килү-килмәү буенча чаралар күрергә

4. Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләр башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. авыл җирлекләре территориясендә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм этноконфессиональ сәбәпле конфликтлы хәлләрне фаразлау өлкәсендә системалы максатчан эш оештыру;

4.2. низаглы хәлләрне ачыклау һәм кисәтү максатларында җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының Зеленодольск муниципаль районы структуралары белән, шул исәптән көч оешмалары, иҗтимагый оешмалар, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлеген оештырырга;

4.3.критик яктан мөһим һәм потенциаль куркыныч объектларны, яшәешне тәэмин итү объектларын һәм җирлек территориясендә урнашкан кешеләр күпләп була торган урыннарны террорчылыкка каршы саклауны тәэмин итү мәсьәләләрен шәхсән контрольгә алырга.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В.Тыгин**